Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең Чәтбаш авылында 2019 елның 8 ноябрендә кабул ителгән 2 нче номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең Чәтбаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында” халык җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Сез

- Чәтбаш авылында су белән цистерна саклау өчен бина төзү;
- Чәтбаш авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында гидрантлар һәм башка материаллар, шулай ук эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;
- Чәтбаш авылында калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту һәм рекультивацияләү

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Чәтбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертү белән килешәсезме? «ӘЙЕ» «ЮК» соравы буенча 08.11.2019 үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенгы беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 32 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 17.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 17 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Чәтбаш авылында хылык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2«Сез

- Чәтбаш авылында су белән цистерна саклау өчен бина төзү;
- Чәтбаш авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында гидрантлар һәм башка материаллар, шулай ук эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;
- Чәтбаш авылында калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту һәм рекультивацияләү

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Чәтбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертү белән килешәсезме? соравы буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.Халык җыены нәтиҗәләрен информацион стендларда һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә.

Кызылтау авыл җирлеге Башлыгы Ш. Р. Гаффаров